| | | |
|---|---|---|
| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 30 декабрь г.Казань № 1349

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Махсус сакланыла торган табигать территорияләрен саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 30 сентябрь, 941 нче карары белән расланган Махсус сакланыла торган табигать территорияләрен саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Махсус сакланыла торган табигать территорияләрен саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 30 сентябрь, 941 нче карары белән расланган Махсус сакланыла торган табигать территорияләрен саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.4 пунктның беренче абзацында татар текстында «дәүләт» сүзе алдына «төбәк» сүзен өстәргә;

1.5 пунктта татар текстында «дәүләт» сүзе алдына «төбәк» сүзен өстәргә;

1.6 пунктта татар текстында «дәүләт» сүзе алдына «төбәк» сүзен өстәргә;

1.8 пунктның беренче абзацында «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» сүзләрен «248-ФЗ номерлы» сүзләренә алмаштырырга;

1.9 пунктның беренче абзацында татар текстында «дәүләт» сүзе алдына «төбәк» сүзен өстәргә;

2.2 пунктның беренче абзацында татар текстында «дәүләт» сүзе алдына «төбәк» сүзен өстәргә;

2.3 пунктның беренче абзацында «Контрольдә тотылучы» сүзләрен «Төбәк дәүләт контролендә (күзәтчелегендә) тотылучы» сүзләренә алмаштырырга;

2.4 пунктның беренче абзацында «3 ел» сүзләрен «өч ел» сүзләренә алмаштырырга;

2.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.7. Төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) объектын риск категориясенә кертү турында карар булмаганда, мондый төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) объектлары түбән рисктагы категориягә кертелгән дип санала.»;

2.8 пунктта «төбәк дәүләт» сүзләре алдындагы «махсус сакланыла торган табигать территорияләрен саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.10. Бирелгән риск категориясенә карап, төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) объектларына карата бу Нигезләмәнең 4.6 пунктында күрсәтелгән планлы контроль (күзәтчелек) чараларын үткәрү түбәндәге вакыт аралыгында гамәлгә ашырыла:

шактый рисктагы объектларга карата – өч елга бер тапкыр (контроль (күзәтчелек) чараларының берсе);

урта рисктагы контрольдә тотылучы объектларга карата – дүрт елга бер тапкыр (контроль (күзәтчелек) чараларының берсе);

уртача рисктагы контрольдә тотылучы объектларга карата – биш елга бер тапкыр (контроль (күзәтчелек) чараларының берсе);

түбән рисктагы категориягә кертелгән дәүләт күзәтчелеге объектларына карата планлы контроль (күзәтчелек) чаралары үткәрелми.»;

2.13 пунктта «төбәк дәүләт» сүзләре алдындагы «махсус сакланыла торган табигать территорияләрен саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә» сүзләрен төшереп калдырырга;

3.1 пунктның беренче абзацында татар текстында «дәүләт» сүзе алдына «төбәк» сүзен өстәргә;

3.2 пунктта татар текстында «челтәрендәге» сүзе алдына «мәгълүмат-телекоммуникация» сүзләрен өстәргә;

3.3 пунктта татар текстында «челтәрендәге» сүзе алдына «мәгълүмат-телекоммуникация» сүзләрен өстәргә;

3.8 пунктта:

дүртенче абзацта «1 тикшерүдә тотылучы» сүзләрен «бер тикшерүдә тотылучы» сүзләренә алмаштырырга;

җиденче абзацта «дәүләт контроле» сүзләре алдына «төбәк» сүзен өстәргә;

сигезенче абзацта «дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру» сүзләре алдына «төбәк» сүзен өстәргә;

унынчы абзацта «8 һәм» сүзләрен «сигез һәм» сүзләренә алмаштырырга;

3.2 пунктта татар текстында «челтәрендә» сүзе алдына «мәгълүмат-телекоммуникация» сүзләрен өстәргә;

3.9 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.9. Профилактик визит дәүләт инспекторы тарафыннан контрольдә тотылучы зат эшчәнлеген гамәлгә ашыру урыны буенча профилактик әңгәмә формасында яисә видео-конференция-элемтә куллану юлы белән уздырыла. Профилактик визит барышында контрольдә тотылучы затка үз вәкаләтләре турында, шулай ук төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) объектына карата үткәрелә торган төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) оештыру һәм гамәлгә ашыру үзенчәлекләре турында хәбәр ителә.»;

өченче абзацта «контрольдә тотылучы» сүзләрен «төбәк дәүләт контролендә (күзәтчелегендә) тотылучы» сүзләренә алмаштырырга;

җиденче абзацта «контрольдә тотылучы» сүзләрен «төбәк дәүләт контролендә (күзәтчелегендә) тотылучы» сүзләренә алмаштырырга;

IV бүлек исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«IV. Төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру»;

4.1 пунктның беренче абзацында «Дәүләт» сүзен «Төбәк дәүләт» сүзләренә алмаштырырга;

4.7 пунктта:

сигезенче абзацта «дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру» сүзләре алдына «төбәк» сүзен өстәргә;

«а» пунктчасында:

беренче абзацта «контрольдә тотылучы» сүзләрен «төбәк дәүләт контролендә (күзәтчелегендә) тотылучы» сүзләренә алмаштырырга;

сигезенче абзацта «1 эш» сүзләрен «бер эш» сүзләренә алмаштырырга;

«в» пунктчасында:

беренче абзацта «дәүләт контроле (күзәтчелеге)» сүзләре алдына «төбәк» сүзен өстәргә;

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әгәр дә документларны тикшерү барышында контрольдә тотылучы зат тарафыннан тапшырылган документларда хаталар һәм (яки) каршылыклар ачыкланса яисә бу документлардагы белешмәләрнең Дәүләт комитетындагы документларда булган һәм (яки) төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда алынган белешмәләргә туры килмәве ачыкланса, хаталар, каршылыклар һәм белешмәләрнең туры килмәве турындагы мәгълүмат, 10 эш көне эчендә кирәкле аңлатмалар бирүне таләп итеп, контрольдә тотылучы затка җибәрелә. Тапшырылган документларда ачыкланган хаталарга һәм (яки) каршылыкларга карата яисә бу документлардагы белешмәләрнең Дәүләт комитетындагы документларда булган һәм (яки) төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда алынган белешмәләргә туры килмәвенә карата Дәүләт комитетына аңлатмалар бирә торган контрольдә тотылучы зат элек тапшырылган документларның дөреслеген раслый торган документларны өстәмә рәвештә Дәүләт комитетына тапшырырга хокуклы.»;

«г» пунктчасында:

икенче абзацта «контрольдә тотылучы» сүзләрен «төбәк дәүләт контролендә (күзәтчелегендә) тотылучы» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Планнан тыш күчмә тикшерү, Дәүләт комитетының төбәк әһәмиятендәге махсус саклана торган табигать территориясенә зарар (зыян) китерү турында яки зарар (зыян) китерү куркынычы турында белешмәләре булганда яисә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) объектының расланган мәҗбүри таләпләрне бозу рискы индикаторлары параметрларына туры килүе ачыкланганда яки төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) объекты мондый параметрлардан тайпылганда, прокуратура органнары белән килештереп үткәрелә.»;

уналтынчы абзацта «контрольдә тотылучы» сүзләрен «төбәк дәүләт контролендә (күзәтчелегендә) тотылучы» сүзләренә алмаштырырга;

4.9 пунктның «а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) Дәүләт комитетының закон тарафыннан сакланыла торган кыйммәтләргә зарар (зыян) китерү турында яки зарар (зыян) китерү куркынычы турында белешмәләре булу яисә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) объектының расланган мәҗбүри таләпләрне бозу рискы индикаторлары параметрларына туры килүе ачыклану яки төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) объекты мондый параметрлардан тайпылу;»;

4.10 пункттагы «а» пунктчасындагы беренче абзацында «контрольдә тотылучы» сүзләрен «төбәк дәүләт контролендә (күзәтчелегендә) тотылучы» сүзләренә алмаштырырга, «Интернет» сүзеннән соң «мәгълүмат-телекоммуникация» сүзләрен өстәргә;

4.11 пунктның «а» пунктчасындагы беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) Дәүләт комитетының закон тарафыннан сакланыла торган кыйммәтләргә зарар (зыян) китерү турында яки зарар (зыян) китерү куркынычы турында белешмәләре булу яисә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) объектының расланган мәҗбүри таләпләрне бозу рискы индикаторлары параметрларына туры килүе ачыклану яки төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) объекты мондый параметрлардан тайпылу.»;

икенче абзацта «контрольдә тотылучы» сүзләрен «төбәк дәүләт контролендә (күзәтчелегендә) тотылучы» сүзләренә алмаштырырга;

4.11 пунктның «в» пунктчасында татар текстында «контрольдә тотылучы» сүзләрен «төбәк дәүләт контролендә (күзәтчелегендә) тотылучы» сүзләрен өстәргә;

V бүлекнең исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«V. Дәүләт комитеты карарларына, төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять бирү;

5.1 пунктта татар текстында «дәүләт» сүзе алдына «төбәк» сүзен өстәргә;

5.5 пунктның дүртенче абзацында «карары» сүзен «карарлары» сүзенә алмаштырырга;

5.9 пунктта татар текстында «дәүләт» сүзе алдына «төбәк» сүзен өстәргә;

VI бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

## «VI. Төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) өчен төп күрсәткечләр һәм аларның максатчан мәгънәләре, индикатив күрсәткечләр

6.1. Төбәк дәүләт контроленең (күзәтчелегенең) төп күрсәткече – язып бирелгән штрафлардан түләтелгән штрафлар өлеше (аның максатчан мәгънәсе – 80 процент күрсәткеченә ирешү).

6.2. Төбәк дәүләт контроленең (күзәтчелегенең) индикатив күрсәткечләре:

1) хисап чорында план буенча үткәрелгән контроль (күзәтчелек) чаралары саны;

2) хисап чорында планнан тыш үткәрелгән контроль (күзәтчелек) чаралары саны;

3) хисап чорында төбәк дәүләт контролендә (күзәтчелегендә) тотылучы объектның мәҗбүри таләпләрне бозу рискы индикаторларында расланган параметрларга туры килүен яки контрольдә тотылучы объектның мондый параметрлардан читкә китүен ачыклау нигезендә планнан тыш үткәрелгән контроль (күзәтчелек) чаралары саны;

4) хисап чорында хезмәттәшлек итеп үткәрелгән контроль (күзәтчелек) чараларының гомуми саны;

5) хисап чорында контроль (күзәтчелек) чараларының һәр төре буенча хезмәттәшлек итеп үткәрелгән контроль (күзәтчелек) чаралары саны;

6) хисап чорында үзара дистанцион хезмәттәшлек итү чараларыннан файдаланып үткәрелгән контроль (күзәтчелек) чаралары саны;

7) хисап чорында үткәрелгән мәҗбүри профилактик визитлар саны;

8) хисап чорында мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куймау турында игълан ителгән кисәтүләр саны;

9) хисап чорында нәтиҗәләре буенча мәҗбүри таләпләрнең бозылуы ачыкланган контроль (күзәтчелек) чаралары саны;

10) хисап чорында йомгаклары буенча административ хокук бозулар турында эшләр кузгатылган контроль (күзәтчелек) чаралары саны;

11) хисап чорында контроль (күзәтчелек) чаралары нәтиҗәләре буенча салынган административ штрафлар суммасы;

12) хисап чорында контроль (күзәтчелек) чараларын үткәрүне килештерү турында прокуратура органнарына җибәрелгән гаризалар саны;

13) хисап чорында контроль (күзәтчелек) чараларын үткәрүне килештерү турында прокуратура органнарына җибәрелгән һәм прокуратура органнары тарафыннан килештерелмәгән гаризалар саны;

14) хисап чоры ахырына исәпкә алынган төбәк дәүләт контролендә (күзәтчелегендә) тотылучы объектларның гомуми саны;

15) хисап чоры ахырына исәпкә алынган, риск категорияләренә кертелгән төбәк дәүләт контролендә (күзәтчелегендә) тотылучы объектларның риск категорияләрендәге һәрберсе буенча саны;

16) хисап чоры ахырына исәпкә алынган контрольдә тотылучы затлар саны;

17) хисап чорында исәпкә алынган һәм аларга карата контроль (күзәтчелек) чаралары үткәрелгән контрольдә тотылучы затлар саны;

18) хисап чорында контрольдә тотылучы затлар тарафыннан судка кадәрге тәртиптә бирелгән шикаятьләрнең гомуми саны;

19) хисап чорында контрольдә тотучы (күзәтчелек итүче) орган тарафыннан карап тикшерү срогы бозылган шикаятьләр саны;

20) хисап чорында контрольдә тотылучы затлар тарафыннан судка кадәрге тәртиптә бирелгән, карап тикшерү йомгаклары буенча контрольдә тотучы (күзәтчелек итүче) органның карарын тулысынча йә өлешчә гамәлдән чыгару турында яисә контрольдә тотучы (күзәтчелек итүче) органнарның вазыйфаи затлары гамәлләрен (гамәл кылмавын) гамәлдән чыккан дип тану турында карар кабул ителгән шикаятьләр саны;

21) хисап чорында контрольдә тотылучы зат тарафыннан Дәүләт комитетының карарлары белән, вазыйфаи затларының гамәлләре (гамәл кылмавы) белән килешмәү турында җибәрелгән дәгъва гаризалары саны;

22) хисап чорында контрольдә тотылучы зат тарафыннан Дәүләт комитетының карарлары белән, вазыйфаи затларының гамәлләре (гамәл кылмавы) белән килешмәү турында җибәрелгән, белдерелгән таләпләрне канәгатьләндерү турында карар кабул ителгән дәгъва гаризалары саны;

23) хисап чорында төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) оештыруга һәм гамәлгә ашыруга карата таләпләрне тупас бозып үткәрелгән һәм нәтиҗәләре дөрес түгел дип танылган һәм (яки) гамәлдән чыгарылган контроль (күзәтчелек) чаралары саны.»;

VII бүлек үз көчен югалткан дип танырга.

2. Бу карар (бу карарның 2022 елның 1 мартыннан үз көченә керә торган 1 пунктында күрсәтелгән Нигезләмәнең VI бүлегеннән тыш) имза куелган көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин